**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об образовании Республиканского организационного комитета по подготовке и проведению ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани

В связи с изданием Указа Президента Российской Федерации от 17 января 2023 года № 17 «О Международном экономическом форуме «Россия – Исламский мир: KazanForum», в целях организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений при подготовке и проведении ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани **постановляю:**

1. Образовать Республиканский организационный комитет по подготовке и проведению ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани.

2. Утвердить Положение о Республиканском организационном комитете по подготовке и проведению ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

создать оперативный штаб по подготовке и проведению ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани;

создать рабочие группы по отдельным направлениям подготовки и проведения ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани;

привести свои правовые акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

4. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 11 декабря 2015 года № УП-1193 «О Международном экономическом саммите «Россия – Исламский мир: KazanSummit».

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
21 января 2023 года
№ УП-39

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «21» января 2023 года

№ УП-39

**Положение
о Республиканском организационном комитете по подготовке
и проведению ежегодного Международного экономического форума
«Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани**

## I. Общие положения

1. Республиканский организационный комитет по подготовке и проведению ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани (далее соответственно – Республиканский оргкомитет, Форум) является коллегиальным органом, образованным в целях организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан (далее – территориальные органы федеральных органов исполнительной власти), органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), организаций и общественных объединений при подготовке и проведении Форума.

2. Республиканский оргкомитет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

## II. Основные задачи Республиканского оргкомитета

3. Основными задачами Республиканского оргкомитета являются:

а) разработка и утверждение республиканского плана мероприятий по подготовке и проведению Форума;

б) анализ хода реализации планов, программ и отдельных мероприятий, связанных с подготовкой к проведению Форума, обеспечение контроля за выполнением республиканского плана мероприятий по подготовке и проведению Форума и целевым использованием финансовых средств, выделенных на его реализацию;

в) разработка предложений по организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного

самоуправления, организаций и общественных объединений в процессе реализации принятых Республиканским оргкомитетом решений и оценка их эффективности;

г) организация взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений при решении задач, связанных с выполнением республиканского плана мероприятий по подготовке и проведению Форума.

4. Республиканский оргкомитет в целях реализации стоящих перед ним задач имеет право:

а) запрашивать и получать в соответствии с законодательством от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений информационные материалы по вопросам, относящимся к компетенции Республиканского оргкомитета;

б) создавать в установленном порядке рабочие группы для решения вопросов, относящихся к компетенции Республиканского оргкомитета;

в) приглашать в установленном порядке на свои заседания руководителей и иных представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, организаций, общественных объединений и прочих заинтересованных лиц;

г) направлять своих представителей для участия в совещаниях, конференциях и семинарах по вопросам подготовки и проведения Форума.

## III. Состав Республиканского оргкомитета

5. Состав Республиканского оргкомитета утверждается Президентом Республики Татарстан.

6. В состав Республиканского оргкомитета входят председатель, заместители председателя, секретарь и иные члены Республиканского оргкомитета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

7. Председателем Республиканского оргкомитета является Президент Республики Татарстан.

8. Председатель Республиканского оргкомитета:

а) руководит работой Республиканского оргкомитета, определяет перечень, сроки и порядок рассмотрения вопросов на заседаниях Республиканского оргкомитета;

б) распределяет полномочия (обязанности) между заместителями и членами Республиканского оргкомитета;

в) определяет и утверждает повестку дня, дату, время и место проведения заседаний;

г) назначает на время своего отсутствия одного из заместителей исполняющим обязанности председателя Республиканского оргкомитета;

д) подписывает протоколы заседаний и другие документы Республиканского оргкомитета.

9. Секретарь Республиканского оргкомитета:

а) принимает участие в заседаниях Республиканского оргкомитета;

б) уведомляет членов Республиканского оргкомитета о месте, дате, времени проведения заседания не менее чем за пять дней до дня проведения заседания, рассылает повестку дня заседания;

в) отвечает за подготовку протоколов заседаний и других документов Республиканского оргкомитета.

10. Члены Республиканского оргкомитета:

а) участвуют лично в заседаниях Республиканского оргкомитета;

б) выносят на обсуждение предложения по вопросам, находящимся в компетенции Республиканского оргкомитета;

в) осуществляют иные мероприятия по подготовке, исполнению решений Республиканского оргкомитета.

## IV. Заседания и решения Республиканского оргкомитета

11. Заседания Республиканского оргкомитета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в квартал.

12. Заседания Республиканского оргкомитета ведет председатель или по его поручению один из заместителей председателя.

13. Заседание Республиканского оргкомитета считается правомочным, если в нем принимают участие более половины его членов. Решение Республиканского оргкомитета считается принятым, если за него проголосовало не менее половины членов, присутствующих на заседании. При равенстве голосов голос председательствующего является решающим. По результатам рассмотрения вопросов повестки дня и голосования на заседании Республиканского оргкомитета принимаются решения, которые оформляются протоколом. Протокол заседания Республиканского оргкомитета подписывается председательствующим.

14. Решения, принимаемые Республиканским оргкомитетом, доводятся до заинтересованных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений, иных заинтересованных лиц для руководства при осуществлении текущей деятельности.

## V. Обеспечение деятельности Республиканского оргкомитета

15. Материально-техническое, документационное, информационное и иное обеспечение деятельности Республиканского оргкомитета осуществляется Агентством инвестиционного развития Республики Татарстан.

---

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «21» января 2023 года

№ УП-39

**Состав
Республиканского организационного комитета по подготовке и проведению ежегодного Международного экономического форума «Россия – Исламский мир: KazanForum» в городе Казани**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Республиканского организационного комитета |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Республиканского организационного комитета |
| Сафаров Асгат Ахметович | Руководитель Администрации Президента Республики Татарстан, заместитель председателя Республиканского организационного комитета |
| Минуллина Талия Ильгизовна | руководитель Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан, секретарь Республиканского организационного комитета |
| Аглиуллин Фаниль Анварович | министр земельных и имущественных отношений Республики Татарстан |
| Айзатуллин Марат Мансурович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Аксаков Анатолий Геннадьевич | председатель Комитета Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации по финансовому рынку (по согласованию) |
| Ахметшин Равиль Калимуллович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Полномочный представитель Республики Татарстан в Российской Федерации |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Бакиров Газинур Тальгатович | помощник Президента Республики Татарстан |
| Бурганов Рафис Тимерханович | ректор федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма» (по согласованию) |
| Вахитов Радик Рафикович | представитель Министерства иностранных дел Российской Федерации в городе Казани (по согласованию) |
| Габдрахманова Гульнара Закариевна | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по архивному делу |
| Гайзатуллин Радик Рауфович | министр финансов Республики Татарстан |
| Гайнутдинов Равиль Исмагилович | председатель Централизованной религиозной организации Духовного управления мусульман Российской Федерации (по согласованию) |
| Гараев Зуфар Фанилович | председатель правления Акционерного коммерческого банка «АК БАРС» (публичное акционерное общество) (по согласованию) |
| Гараев Марат Масгутович | начальник Татарстанской таможни (по согласованию) |
| Гафаров Шамиль Хамитович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Руководитель Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Гаязов Зуфар Фадипович | президент Ассоциации Рестораторов и Отельеров г. Казани и Республики Татарстан (по согласованию) |
| Губайдуллин Эмиль Фидаилевич | генеральный директор автономной некоммерческой организации «Центр развития профессиональных компетенций» (по согласованию) |
| Денисов Максим Сергеевич | генеральный директор автономной некоммерческой организации «Дирекция спортивных и социальных проектов» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Зарипова Эльмира Амировна | министр труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан |
| Зяббаров Марат Азатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |
| Иванов Сергей Евгеньевич | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по туризму |
| Камалтынов Юрий Зимелевич | заместитель Председателя Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Коробченко Олег Владимирович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Леонов Владимир Александрович | министр спорта Республики Татарстан |
| Маврина Лилия Николаевна | Секретарь Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Метшин Ильсур Раисович | глава муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Миннегалиев Роберт Хамитович | генеральный директор автономной некоммерческой организации «Центр развития и поддержки конгрессно-выставочных, культурных, зрелищно-развлекательных, спортивно-массовых и социально-ориентированных мероприятий «Казань Экспо» (по согласованию) |
| Кирилл (Наконечный Михаил Васильевич) | митрополит Казанский и Татарстанский (по согласованию) |
| Насибуллин Назиль Наилович | помощник Премьер-министра Республики Татарстан по внешнеэкономической деятельности |
| Нафигин Альберт Ильдарович | помощник Президента Республики Татарстан |
| Патяшина Марина Александровна | руководитель Управления Федеральной службы по надзору в сфере защиты прав потребителей и благополучия человека по Республике Татарстан (Татарстан) (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Романцов<br>Сергей Анатольевич | генеральный директор акционерного общества «Международный аэропорт «Казань» (по согласованию) |
| Савельев<br>Игорь Леонидович | заместитель Руководителя Администрации Президента Республики Татарстан – руководитель Экспертного департамента Президента Республики Татарстан |
| Садыков<br>Марат Наилевич | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Садыков<br>Ринат Наильевич | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Салимгараев<br>Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Самигуллин<br>Камиль Искандерович | муфтий Централизованной религиозной организации – Духовного управления мусульман Республики Татарстан (по согласованию) |
| Сафин<br>Ленар Ринатович | ректор федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Фаррахов<br>Айрат Закиевич | член Комитета Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации по бюджету и налогам (по согласованию) |
| Хабибуллин<br>Рафис Завдатович | начальник Главного управления Министерства Российской Федерации по делам гражданской обороны, чрезвычайным ситуациям и ликвидации последствий стихийных бедствий по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Хадиуллин<br>Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Хайруллин<br>Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Ханифов<br>Фарит Мударисович | министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Хвостиков Игорь Владимирович | начальник Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Хохорин Артем Валерьевич | Министр внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Шагиахметов Мидхат Рафкатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр экономики Республики Татарстан |
| Шадриков Александр Валерьевич | министр экологии и природных ресурсов Республики Татарстан |
| Шайхразиев Василь Габтелгаязович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан |
| Шайхутдинов Роман Александрович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан |
| Шарифуллин Марат Дамирович | управляющий Отделением – Национальным банком по Республике Татарстан Волго-Вятского главного управления Центрального банка Российской Федерации (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы турында» 2023 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы Указы чыгарылу белән бәйле рәвештә, Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзергә.

2. Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча оператив штаб төзергә;

Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыруның аерым юнәлешләре буенча эш төркемнәре төзергә;

үз хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны үтәүне тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммиты турында» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1193 номерлы Указы үз көчен югалткан дип таныргa.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 21 гыйнвар
№ ПУ-39

Татарстан Республикасы
Президентының
2023 елның «_21_» гыйнварындагы
ПУ-_39___ номерлы Указына
1 нче кушымта

**Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба тиешенчә – Республика оештыру комитеты, Форум) – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының (алга таба – федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Форумны әзерләгәндә һәм уздырганда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган.

2. Республика оештыру комитеты Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасының законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

3. Республика оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Форумны әзерләү һәм уздыру буенча чараларның республика планын төзү һәм раслау;

б) Форумны үткәрүгә әзерлек белән бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыру барышын анализлау, Форумны әзерләү һәм уздыру буенча чараларның республика планы үтәлешен һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны тәэмин итү;

в) Республика оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә

органнарының, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

г) Форумны әзерләү һәм уздыру чараларының республика планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру.

4. Республика оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны хәл итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә Республика оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) кирәк булган очракта Республика оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен эш төркемнәре төзергә;

в) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен, аларның башка вәкилләрен һәм кызыксыну белдергән бүтән затларны билгеләнгән тәртиптә чакырырга;

г) үз вәкилләрен Форумны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашырга җибәрергә.

## III. Республика оештыру комитеты составы

5. Республика оештыру комитеты составын Татарстан Республикасы Президенты раслый.

6. Республика оештыру комитеты составына Республика оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнашучы башка әгъзалары керә.

7. Татарстан Республикасы Президенты Республика оештыру комитеты рәисе булып тора.

8. Республика оештыру комитеты рәисе:

а) Республика оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Республика оештыру комитеты утырышларында каралачак мәсьәләләрне, аларны карау срокларын һәм тәртибен билгели;

б) урынбасарлары һәм Республика оештыру комитеты әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүлә;

в) көн тәртибен, утырышларны үткәрү датасын, урынын һәм вакытын билгели һәм раслый;

г) үзе урында булмаган вакытта урынбасарларының берсен Республика оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп билгели;

д) Республика оештыру комитеты беркетмәләренә һәм башка документларга кул куя.

9. Республика оештыру комитеты секретаре:

а) Республика оештыру комитеты утырышларында катнаша;

б) Республика оештыру комитеты әгъзаларына утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында кимендә биш көн алдан хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

10. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

а) Республика оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Республика оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

в) Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

11. Республика оештыру комитеты утырышлары ихтыяҗ туган саен, әмма кимендә кварталга бер тапкыр үткәрелә.

12. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

13. Республика оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, эшчәнлек алып барырга хокуклы дип санала. Республика оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Республика оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү йомгаклары буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

14. Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, кызыксыну белдергән бүтән затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

15. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы башкара.

Татарстан Республикасы
Президентының
2023 елның «_21_»_гыйнварындагы
ПУ-_39_ номерлы Указына
2 нче кушымта

**Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Республика оештыру комитеты рәисе |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, Республика оештыру комитеты секретаре |
| Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Аксаков Анатолий Геннадьевич | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Әхмәтшин Равил Кәлимулла улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Тулы вәкаләтле вәкиле |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |

| | |
|---|---|
| Бакиров<br>Газинур Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Вахитов<br>Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Габдрахманова<br>Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гайзатуллин<br>Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гайнетдинов<br>Равил Исмәгыйль улы | Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Гәрәев<br>Зөфәр Фәнил улы | «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Гәрәев<br>Марат Мәсгут улы | Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |
| Гаязов<br>Зөфәр Фәдип улы | Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы ресторанторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин<br>Эмиль Фидаил улы | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Денисов<br>Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Җәббаров<br>Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Иванов<br>Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Камалтынов<br>Юрий Зимелевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Маврина<br>Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнегалиев<br>Роберт Хәмит улы | «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Кирилл<br>(Наконечный<br>Михаил Васильевич) | Казан һәм Татарстан митрополиты (килешү буенча) |
| Насыйбуллин<br>Назил Наил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының тышкы икътисадый эшчәнлек буенча ярдәмчесе |
| Нәфыйгин<br>Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |

| | |
|---|---|
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Романцов Сергей Анатольевич | «Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Савельев Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Садыйков Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәмигуллин Камил Искәндәр улы | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы мөфтие (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Фәррахов Айрат Зәки улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Бюджет һәм салымнар комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хвостиков<br>Игорь Владимирович | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хохорин<br>Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шадриков<br>Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Шәйхразиев<br>Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Шәйхетдинов<br>Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Шәрифуллин<br>Марат Дамир улы | Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банк идарәчесе (килешү буенча) |

___